УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
К22

Төзүчесе *Рафис Корбан*

**Камал Галиәсгар**

Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. — 302 бит.

Галиәсгар Камалның тууына 125 ел тулу уңаеннан чыгарыла торган бу җыентыкка аның Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат ителгән пьесалары, хикәяләре, үзенең иҗат юлы, язучылык эшчәнлеге хакында сөйләүче һәм шулай ук Г.Тукай турында истәлекләре урын алды.

ISBN 5–298–01375–9

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

ТӨЗҮЧЕДӘН

Галиәсгар Камал әсәрләренең чагыштырмача тулы басмасы моннан чирек гасыр элек, әдипнең тууына 100 ел тулу уңаеннан — 1978, 1979, 1982 елларда, өч томлык «Әсәрләр» җыелмасы буларак нәшер ителгән. Ул томлыклар язучының иҗатын киң колачлап, аның драма әсәрләрен, прозасын, шигырьләрен, эстрада өчен язган лирик, сатирик һәм юмористик миниатюраларын һәм шулай ук матбугатта дөнья күргән мәкалә, рецензия һәм истәлекләрен үз эченә алган.

Язучының 125 еллык юбилее уңаеннан нәшер ителә торган әлеге бер томлык аның иҗатын тулысынча колачларга мөмкинлек бирмәсә дә, без нигездә Г.Камалны аеруча драматург буларак дөньяга таныткан иң күренекле әсәрләрен, шулай ук үз иҗат һәм тормыш юлы хакында сөйләүче истәлек-язмаларын тупладык. Әдипнең драматург буларак иҗаты дөрләп чәчәк аткан һәм татар театры өчен иң талантлы, драматургия классикасына әверелгән әсәрләр иҗат иткән чоры, безнең уебызча, Октябрь инкыйлабына кадәр булган чор.

Г.Камал — 1907 елда Г.Тукай Җаектан Казанга кайтканнан соң, аның белән якын дуслыкта яшәгән шәхесләрнең берсе. Китапка шулай ук ике әдипнең үзара иҗади дуслыгы һәм хезмәттәшлеге хакында бай мәгълүмат биргән «Габдулла Тукай турында истәлек» дигән язмасын урнаштыруны кирәк дип таптык.

Күмерче. Бик һәйбәт шыңгырдап торган өч кап нарат күмере бар. Яратсаң алып кал. Бик шәп күмер. *(Чыга.)*

Кибетче. Күмәч, икмәкне читтән алма. *(Чыга.)*

Әхмәт. Ах, ник өйләндем, нигә дип өйләндем!

*Пәрдә.*

# ХАФИЗӘЛӘМ ИРКӘМ

## Комедия 4 пәрдәдә

УЕНГА КАТНАШУЧЫЛАР:

Хафизә — авылның данлыклы матур кызларыннан.
Хафиз — авылның егетләреннән, ярлы кеше баласы.
Вахит — Хафизәнең атасы.
Хөбби — Хафизәнең анасы.
Кәрим — авыл кулагының улы.
Сиражи — кулак, комитет председателе, Кәримнең атасы.
Сиби
Нигъмәт
Әхмәди
Фатих — авыл егетләре.
Давыт
Баһави
Фазылҗан
Карт — авыл карты.
Мәрфуга
Сәгадәт — авыл кызлары.
Кәримә
Хәмидә
Комиссар.
Старший — отряд башлыгы.
Әби — авылда двор тотучы карчык.
Егетләр, кызлар, кызылармеецлар.

Вакыйга авылда.

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Авылда ындыр арты, яр буе. Суның аргы ягында урманлыклар күренә. Пәрдә ачылганда, сәхнә буш. Бераздан, як-ягына каранып, Кәрим керә.

### Беренче күренеш

Кәрим *(үзалдына сөйләнә)*. Беркем дә юк. Һичбер кем дә минем шикелле ашыкмый. Хафизәләрне киндер тукмаклар өчен монда җыелачаклар, дигәннәр иде, мин, ахры, ашыгыбрак килгәнмендер. *(Бер агач төбенә утыра.)* Кем белә, бәлки, башкалар шикелле булсам, мин дә ашыкмас идем. Ләкин шул мине сөю, көнләшү ашыктыра. Ийе, Хафиз Хафизәне сөя, шулай ук Хафизә дә аны сөя. Мин дә Хафизәне сөям, чын күңелдән сөям, ә Хафизә мине сөйми, Хафизны сөя. Хафизә сөймәслек кыз түгел, аны һәркем дә яратыр, һәм ул шулай сөелергә тиеш тә. Чөнки ул матур, андый матурлар тирә-якларда бик сирәк табылалар. Бәлки, бөтенләй табылмаслар да. Шулай булгач, бер Хафиз гына аны нишләп яратмасын, аның Хафизәне яратуы бер дә гаҗәп түгел. Тик менә Хафизәнең миңа күз төшермичә, шул шыр ялангач ярлы Хафизны сөюенә генә бер дә акылым җитми. Ничә тапкыр яучы җибәртеп карадым, берсен дә кабул итми. Миңа, Хафизәне кулга төшерү өчен, Хафизны юлдан алып ташлаудан башка бер чара да юк. Ни булса да булсын. Миңа аны юл өстеннән алып ташларга кирәк, аннан соң, бәлки, мин Хафизәне үземә карата алырмын. *(Бер якка карап.)* Сиби килә, минем бердәнбер дусым. Аңар сер сыя, башка егетләрнең берсенә дә ышаныр хәл юк. Барысы да аума халыклар. Эчертеп, исертеп сыйлаганда, һәммәсе дә сиңа дус булып, әллә ниләр эшләргә вәгъдәләр кылалар, айныгач, макмыр башларыннан бар вәгъдәләре дә очып беткән була.

Сиби керә.

**Икенче күренеш**

Сиби. Нихәл, иптәш, монда берьялгызың гына, әвене янган кеше шикелле, борыныңны салындырып, ни эшләп утырасың? Без сине тегендә, чишмә янында, килер әле, дип көтеп утырабыз. Анда безнең иптәшләр, гармуннар белән әйттереп, ду килеп утыралар, мин әле монда нихәлләр бар икән дип белергә генә килгән идем. Әле берәү дә юк икән, кызлар да килмәгәннәр. Әллә бүген киндерне башка җирдә тукмакларга булганнар микән?

Кәрим. Килерләр әле. Синең белән мин генә бит ул бик борчылабыз. Башка һичбер кемнең дә җаннарын борча ашамый.

Сиби. Ашамыймы соң, бик нык ашый, бары тик син генә аны шулай дип уйлыйсың. Йә, сөйлә әле, иптәш, нихәлләр бар, ниләр бар? Бу арада синең белән күрешеп сөйләшә дә алган юк. Яңарак хәбәрләр юкмы?

Кәрим. Ни булсын, берни дә юк.

Сиби. Теге беркөн түбән очта булган җыелыштан бирле Хафизәне күргәнең юкмы?

Кәрим. Юк, күргәнем юк. Нигә? Әллә берәр төрле яңарак эшләр булганмы?

Сиби. Юк, алай артык яңа эшләр булганы юк. Тик болай гына, үзем генә әйтәм, берәр төрле ятрак, яңарак эшләр юкмы, дим. Хафизны үз тирәсенә шактый гына күп ишләр җыйган, дип сөйлиләр. Җыен ярлы-ябагайлар аның тирәсенә җыелганнар, ди. Аннан соң тагын, алар Хафиз белән Хафизәне мактап бер яңа көй, бәетләр дә чыгарганнар, ди. Бүген монда киндер тукмаклаган җирдә шуны җырламакчы булалар икән. Түбән очның Исми Хәйрие көйләрен дә отып кайткан. Безнекеләр дә анда, чишмә янына җыелып, шул көйгә салып, Хафизны яманлап бәет чыгара калдылар. Бик күңелле такмаклар тезәләр. Мин сине эзләп монда килдем. Әйдә, кызлар җыелганчы, шунда, алар янына барыйк та аннан соң егетләр белән бергәләп җыелып монда киләбез.

Кәрим. Анда ничек, безнең яклы егетләр күпме?

Сиби. Байтак бар. Мин киткәч, бәлки, тагын да җыелганнардыр әле. Безнең як күп булыр. Бөя бөяргә дә җитәр. Әйдә киттек.

Кәрим. Әйдә алайса, киттек.

Китәләр. Пауза. Хәмидә белән Мәрфуга керәләр.

**Өченче күренеш**

Хәмидә. Әбәү! Монда бер кеше дә юк ич! Мин бая ук инде Шәмкиләргә кергән идем, Хөбби абыстай: «Безнең Әсма инде бая ук, әллә кайчан ук, киндер тукмаклаган җиргә китте», — дигән иде. Әллә ул туп-туры Сәрбиләргә китте микән? Бәлки әле кызлар шунда җыелганнардыр?

Мәрфуга. Юк, ул Гайниҗамалларга кергәндер. Гайниҗамал аның «дусым»ы бит. Шуның белен бергә килә торганнардыр. Һи, бу кызларны да әйтер идем шул, үзләре киндер тукмаклыйбыз дип йөргән булалар, ничә көннән бирле сөйләнеп йөриләр, ә үзләре таганнарын да асып әзерләп куймаганнар. Болар соң таганны кайда гына асмакчы булдылар икән? Бер дә әзерләгән нәрсәләре күренми. *(Агачтагы бауларын күреп.)* Ә, менә икән, менә, элгәкләре дә бар. Монда әзерләгәннәр икән. Асарга бүрәнәсе генә кирәк.

Хәмидә. Менә монда бер бүрәнә кисәге дә бар, шулдыр инде, шуны асмакчы булганнардыр. Бу бик кыска бит, монда ничә генә буй тукмакларлар икән?

Мәрфуга *(карап)*. Шул бик җиткән инде, алты тукмак белән тукмакларлык булгач, ярый. Бүген көннең актыгы түгел әле. Озаккарак сузылса, тагы да күңеллерәк булыр. Хәзер инде авыр эш вакыты да, урак өсте дә түгел. Ашлык коела дип куркасы юк. Әнә кызлар да җыела башладылар, Кәримә белән Сәгадәт тә килә.

Кәримә белән Сәгадәт керәләр.

Хәмидә *(Сәгадәткә)*. Гармуныгызны ничек алып килмәдегез?

Сәгадәт. Минем гармун туганымнарда иде. Беркөн абыз әти ачулангач, ватып якмасын дип куркып, аларга илтеп куйган идем. Әле тукмаклый башламаган икәнсез.

Хәмидә. Без нәрсә тукмаклыйк? Безнең киндер дә, тукмак та юк. Без бүген бит Сәрбинең бирнәгә дип әзерләгән нечкә киндерләрен тукмакларга гына килдек.

Сәгадәт. Кара әле, сез ишеттегезме әле, Хафиз белән аның иптәшләре Хафизәне мактап яңа көй чыгарганнар. Көйләре дә, җырлары да бик матур. Хафизәне бөтенләй күккә күтәргәннәр. Бүген монда кызлар җыелгач, шуны җырламакчы булалар, ди. Җырларын тыңларга түбән оч кызлары белән егетләре дә менмәкче булалар икән. Җырларының берничәсен мин дә отып алдым. Мин инде ул көйне гармунда да уйный белә башладым.

Хәмидә. Син юкка гына гармуныңны алып килмәгәнсең, уйнап күрсәткән булыр идең.

Сәгадәт. Егетләр килгәч уйнарлар әле, ишетербез. Мин алар шикелле үк матур итеп уйный белмим әле. Хафизның Хафизә белән йөргәненә Сираҗи Кәрименең бик ачуы килә икән, ди. «Мин, — дип әйтә икән, ди, — ни эшләсәм дә эшләрмен, шул Хафизәне Хафиз кулыннан тартып алмасам, дөньяда исемем Кәрим дә булмасын, дөньясында йөрмим дә», — дип әйтә икән, ди.

Мәрфуга. Аның шул булыр инде, фитнәнең. Байлыгына масайган була да, әллә кем булган булып, борынын чөеп йөри. Прсидәтел улы булгач та, үзен әллә кем дип исәпли, Сираҗиның байлыгы аның бер айлык. Йә, әйдәгез инде, кызлар да килеп җитәрләр, без бүрәнәне рәтләп, күтәреп асып куя торыйк. Ә, әнә, Сәрбиләр дә киләләр, туганым да килә, әйдәгез, элик.

Кызлар. Әйдәгез.

Нечкәрәк бер бүрәнәне бергәләшеп күтәреп, җирдән ярты аршин биеклектә итеп бауга эләләр. Сәрби һәм берничә кыз бер төргәк киндер һәм тукмаклар күтәреп керәләр.

Сәрби. Әле кызлар шулай гынамыни?

Сәгадәт. Тукмак тавышлары ишетелә башлагач җыелырлар әле. Кояш баер вакыт та җитеп килә. Тизрәк кызларга хәбәр бирә башларга кирәк. Аларның кайсыберләре әле, бәлки, безнең монда җыелачагыбызны да белми торганнардыр.

Хәмидә. Әйдәгез алайса, эшкә башлыйк.

Сәрби. Әйдәгез. *(Киндерләрне җәеп тукмакларга керешәләр.)*

Сәгадәт *(бераз тукмаклагач, туктаган арада).* Безнең монда киндерне гел бер генә төрле көй белән тукмаклыйлар. Аны әллә ничә төрле көй белән тукмаклый торган җирләр дә бар икән. Мин былтыр әниләр белән кодагыйларга кунакка барган идем, шунда ишетеп кайттым. Ничә тукмак белән тукмаклаганнардыр, ул кадәресен белә алмадым. Авылның икенче башында тукмаклыйлар иде. Барып карый алмадым. Әмма соң инде тавышлары шулкадәр матур булып ишетеләдер иде! Һич сөйләп тә бетергесез менә. Шулкадәр моң, шулкадәр күңелле! *(Яңадан тукмаклый башлыйлар.)*

Хәмидә. Кара әле, туганым, кайбер якларда бөтенләй киндер сукмый торган җирләр дә бар икән. Абый сөйләде. Абый әйтә: «Без салдатта хезмәт иткән җирдә, ди, киндер бер дә юк, ди. Һәмме кеше дә ситсы белән йоннан гына киенәләр, ди. Анда сөлге-эскәтер сугучылар да юк, ди. Ыштыр чорнап, чабата-оек киеп йөрүчеләр дә юк, ди. Сала кешеләре дә суканы күн итек киеп сукалыйлар, ди. Анда бездәге шикелле агач сукалар да юк, ди. Торганы сабан гына. Ашлыкны да машина белән уралар, печәнне дә ат җигеп, машина белән чабалар», — ди. Менә рәхәт, ә? Дөньяда шундый җирләр дә бар икән.

Сәгадәт. Булмый ни, бардыр шул. Ул гына түгел әле, җитен киндерен чуарлап суга торган җирләр дә бар икән. Аларның суккан киндерләрен минем дә күргәнем бар. Нәкъ менә сәрфинкә шикелле вак шакмаклы була икән.

Сәрби. Базарда минем дә күргәнем бар. Бер марҗа кигән иде. Аларны әллә кайсы яктан шунда, читтән килгәннәр, диделәр. Яңа җиргә күчеп баручылар, диделәр. Яңа җиргә дигәннәре кайдадыр инде, ул кадәресен мин белмим. Нәкъ менә чуар ак яулык шикелле шакмаклы иде.

Яңадан тукмаклый башлыйлар. Бераздан еректан, «Хафизәләм» көен уйнап, җырлап килгән тавышлар ишетелә, ләкин сүзләре аңланмый.

Сәгадәт. Киләләр, киләләр, теге яңа көйне, Хафизә көен җырлыйлар бугай, бик матур көй икән. Әгәр дә Хафизә бу көйне үзе ишетсә, бер дә урынында басып тора алмас иде. Үрле-кырлы сикерер иде. Хәер лә, ишеткәндер инде, бер генә түгел, әллә ничә тапкыр ишеткәндер. Кичә егетләр, җыелышып, өй түрләреннән җырлап узганнар, ди. Анда әле, Хафизәдән дә бигрәк, Кәрим үрле-кырлы сикерә, ди. Бөтенләй кая барып бәреләсен дә белми, ди. Кәрим инде берничә көннән бирле кемне күрсә, шуны сыйлап, үзенә ишләр дә җыя башлаган, ди...

Хәмидә. Йә, әйдәгез, тукмаклыйк әле, тавыш бирик.

Тукмаклыйлар. Еректан түбәндәге җыр тавышлары ишетелә.

Олы юлдан атлар чаба, ком буранын туздырып,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, ком буранын туздырып.
Матур егет пар кыз таба, йөрми гомер уздырып,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, йөрми гомер уздырып.

Хафизәнең матурлыгы тирә-юньгә дан булган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, тирә-юньгә дан булган.
Хафизә кулга эләкмәгәч, Кәрим күзе кан булган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим күзе кан булган.

Хафиз егет Хафизәне тулган айга охшата,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, тулган айга охшата.
Кәрим йөрәк кайгыларын яшен түгеп бушата,

Хафизәләм иркәм, аппагым ла, яшен түгеп бушата.

Хафизә озын чәчләренә чәч тәңкәләр тезә икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, чәч тәңкәләр тезә икән.
Хафизәнең кайгысына Кәрим ничек түзә икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим ничек түзә икән.

Җырлап керәләр.

Хафизәнең ак яулыгын чайкаганда су алган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, чайкаганда су алган.
Хафизә күзен салмагачтыр, Кәрим башы чуалган,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим башы чуалган.

Нигъмәт *(кереп)*. Ягез, кызларның асыллары, без килгәч кенә нишләп туктадыгыз? Бик матур итеп тыкырдататадыр идегез бит әле. Каравылчы Төхфи бабай шакылдавыгыннан бер дә ким түгел иде.

Хәмидә. Без түгел әле, сез үзегез туктадыгыз. Кәримнең борынына бер-икене чиерткәч тә, шуның белән эш беттемени?

Нигъмәт. Инештә су бетмәсә, бездә җыр бетмәс. *(Бер озын кәгазь күрсәтеп.)* Менә ул бездә никадәр әле. Ятлап та бетерерлек түгел.

Хәмидә. Йә әле, Нигъми абый, бик күңелле икән, тагын бер җырлагыз әле.

Нигъмәт. Сез дә безгә кушылып, бергәләп җырлыйсызмы? Безгә кушылып җырласагыз, җырларбыз.

Кызлар *(бергә)*. Җырлагыз, җырла, кушылабыз, кушылабыз.

Нигъмәт. Әйдәгез, егетләр, матур кызларның сүзләре җирдә калмасын. Калганын җырлыйбызмы?

Егетләр. Җырлыйбыз, җырлыйбыз, актыгына кадәр җырлыйбыз. *(Җырлыйлар.)*

Хафизәнең баш яулыгы аллы-гөлле буйлы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, аллы-гөлле буйлы икән.
Хафизә кулдан ычкынгачтын, Кәрим ниләр уйлый икән?
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Кәрим ниләр уйлый икән?

Кәрим ниләр уйлый икән? — утрып, үкреп җылый икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, утрып, үкреп җылый икән.
Хафизә — Хафиз кочагында, Хафиз куены җылы икән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Хафиз куены җылы икән.

Нигъмәт. Йә инде, кызлар, күңелегез булдымы?

Хәмидә. Рәхмәт сезгә.

Нигъмәт. Без сезнең сүзне тыңладык. Инде сез дә безнең сүзне тыңлагыз. Йә, инде бер матур гына итеп киндер тукмаклап алыгыз.

Сәгадәт. Ярый, тыңлыйбыз. Әйдәгез, кызлар.

Тукмаклый башлыйлар. Егетләрнең кайсы чүгәләп, кайсы агачларга сөялеп карап торалар.

Әхми *(бераздан, уң якны күрсәтеп).* Егетләр, егетләр, әнә Хафиз үзе дә килә. Әйдәгез, егетләр, җырлап каршы алабыз.

Нигъмәт *(як-якка каранып)*. Кая? Ә, менә бу яктан Хафизә дә килә. Әйдә, башлагыз!

Күмәк җыр.

Югары очтан берәү килә, Хафизәнең атлавы,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Хафизәнең атлавы.
Батыр егет, матур кызны бик күңелле мактавы,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бик күңелле мактавы.

Хафизә — кызлар янына, Хафиз егетләр янына килеп туктыйлар. Хафиз белән Хафизә ымлашып исәнләшәләр.

Хафиз. Исәнмесез, иптәшләр! Сез нишләп бездән көләсез?

Әхми. Безме? Һич юк, без нишләп синнән көлик? Бер дә көлмибез. Ә әнә анда, тегендә, Кәрим ялчылары бездән көләргә дип җыенып йөриләр, ди. Чишмә буенда, безне мыскыл итеп, бәет чыгарып яталар, ди. Сиби дә шунда, ди. Кәрим кичә төн буена аларны эчертеп, сыйлап чыккан, ди. Без шуны ишеттек тә монда җыелып килдек. Киндер тукмаклаган җиргә алар да килми калмаслар. Әгәр дә андый-мондый мыскыл итә калсалар, без дә аларга бирешмәбез.

Хафиз. Рәхмәт.

Нигъмәт. Ягез инде, кызлар, нишләп сез, без килгәч кенә, тукмаклаудан туктадыгыз? Әйдә тыкырдатыгыз. Мин дә сезнең тукмак көенә басып биеп алырмын.

Кызлар, җыелып, киндер тукмаклый, егетләрнең берсе гармун уйный. Нигъмәт бии башлый.

Тыкыр-тыкыр, тыкыр-тыкыр, кызлар киндер тукмаклый,
Кызлар киндер тукмаганны безнең китап бик мактый.

Биюендә дәвам итеп.

Әйдә, кызлар, булышыгыз, бергә салыйк сукмакны,
Дус шатлыктан кулын чаба, дошман көя, ух-ах, ди.
Бие, бие син, егет, такырайт ындыр табагын,
Бии белмәгән җырласын, кызганмасын тамагын.

Сиби кереп яшеренеп тора. Егетләр белән кызлар кара-каршы бии башлыйлар. Хафиз, Хафизә янына килеп, башы белән ымлап, Хафизәне бер читкә алып китә.

Хафиз. Хафизә, сиңа сөйлисе бик күп сүзләр бар. Бүген кич күрешеп сөйләшергә вакыт таба алырсыңмы?

Сиби, яшеренгән җиреннән күренмичә генә чыгып, Хафизәләр артына яшеренеп, сүзләрен тыңлап тора.

Хафизә. Хафиз, син бүгенгә генә сабыр ит инде. Бүген моннан да бик соң кайтылыр. Аның өстенә тагы бүген әни минем монда килүемә дә бик борчылып калды. Кичә кемнәрдер урамнан безнең турыда чыгарылган көйне уйнап, җырлап уздылар. Ахрысы, әниләр шуны ишеткәннәрдер. Әни бүген көн буена миңа ачуланып, караңгыланып йөрде. Син иртәгә кич, мәзин ясигыга азан әйткәч тә, безнең келәт артына кил. Шул вакытта мин дә чыгармын, иркенләп сөйләшербез. Ләкин, кара аны, зинһар, дип әйтәм, бик сак була күр, Кәримнәр сине күрмәсеннәр. Болай да әле ул ачуыннан тиресенә сыя алмыйча йөри. Йә, ярый, бар инде, читкәрәк кит, һәммәсе дә безгә күз салып карап торалар.

Хафиз. Ярый алайса, мин иртәгә шул син әйткән вакытта килермен, син, зинһар, чыкмыйча кала күрмә, сөйлисе сүзләр бик күп.

Хафизә. Ярар.

Хафиз. Хәзергә хуш.

Хафизә. Хуш. *(Хафиз егетләр арасына китә.)*

Нигъмәт. Бии торгач, корсактагы ашаган ипиләр дә коелып бетте. Тукмак көенә басу бик күңелле икән. Моннан соң инде бу көйне «Тукмак көе» дип әйтербез.

Фазылҗан. Ягез, әйдә, кызган юлы кызсын инде.

Ерактан җыр һәм гармун тавышы килә.

Әхми. Аһа, егетләр, иптәшләр, теге оч егетләре, ак чабата-ак оеклар менеп киләләр. Әгәр дә безне тешләп җырласалар, яхшы карагыз, бер дә бирешмәгез, бер урынына ун җавап кайтарырга тырышыгыз.

Нигъмәт. Хафаланма, бирешмәбез, тырышырбыз, әгәр дә бик ачуны китерсәләр, мәми авызларының салма савытларына менеп төшәргә дә бик кыйбат алмабыз.

Җыр тавышы якыная бара.

Әхми. Әһә, егетләр, араларында Кәрим дә бар. Ахры, үзләрен сыйларга да өлгергәндер, бик болагайланып киләләр.

Нигъмәт. Болагайлансыннар! Алар болагайлансалар, без аларга уңагайлап та җибәрә белербез.

Хафиз. Анысы шулаен шулай да, ләкин эш зурга китеп бармасын. Исерекләр белән сугышып йөрү яхшы түгел. Әгәр дә бәйләнә башласалар, китүебез яхшы булыр.

Нигъмәт. Бер дә курыкмагыз. Кара-каршы әйтешмичә китте-митте юк, кирәк булса, бәргәләшеп тә алырбыз.

Кәрим партиясе *(җырлап керә)*.

Хафиз киткән ил буена, илдән хәер сорарга,
Хафиз бүкән, апара корсак, илдән хәер сорарга.
Хафизә балчык эзләп йөри ватык чүлмәк сыларга,
Хафизә бүкән, апара корсак, ватык чүлмәк сыларга.

Хәмидә *(Хафизәгә)*. Әйдә, Хафизә, без тизрәк, яхшы чагында моннан китик, күрәсең алар нинди исерекләр.

Хафизә. Сугыш-фәлән чыгарып, Хафизларны харап итмәсләр микән?

Хәмидә. Син алар өчен кайгырма, Хафизның иптәшләре әле җитәрлек. Алар ул исерекләргә генә бирешмәсләр. *(Китә башлаган кызларны күрсәтеп.)* Әнә күрәсең, бар кызлар да китеп бетәләр.

Хафизә. Әйдә алайса. *(Китә башлыйлар.)*

Сиби *(качып торган җиреннән чыгып, Кәрим партиясенә кушылып).* Туктагыз, кызлар, кайда качасыз? Без бит аю түгел, ашамабыз.

Хәмидә. Күзле бүкәннәр! Кыйланышлары! Җирәнгечләр! Бер тиенлек эчеп, егерме тиенлек исергәннәр. *(Китәләр.)*

Кәрим. Кызлар, туктагыз әле, ник китәсез?

Кәрим партиясе *(җырлый).*

Хафизәләрнең капкасын
Калмаган ди ачасы,
Хафизә лә бүкән, ачык авыз,
Калмаган ди ачасы.
Ачык капкаларны күргәч,
Килә ташлап качасы,
Хафизә лә бүкән, ачык авыз,
Килә ташлап качасы.

Көләләр.

Хафиз партиясе *(җырлый).*

Аргы яктан болыт килә,
Яшен яшьнәп, камчылап.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Яшен яшьнәп, камчылап.
Бай баласы Кәрим елый,
Яше ага тамчылап.
Хафизә матур эләкмәгәч,
Яше ага тамчылап.

Кәрим партиясе *(җырлый).*

Аргы якның егетләре,
Авызлары селәгәй;
Хафизә, сөрт авызларын —
Авызлары селәгәй.
Хафиз малай ач бетләре
Йөри булып күләгәй.
Хафизә, кара, күрмисеңме?
Йөри булып күләгәй.

Хафиз партиясе *(җырлый).*

Кәрим, Кәрим-кәрләләргә
Әллә ниләр кирәкми.
Хәфизәләм иркәм, аппагым ла,
Әллә ниләр кирәкми.
Айдай матур Хафизәләр
Кәримнәргә эләкми.
Хафизәләм иркәм, аппагым ла,
Кәримнәргә эләкми.

*(Барысы бердән.)* Ха, ха, ха. ха!

Кәрим. Авызыгызны җыя төшегез, малайлар! Юк исә тешләрегезне җирдән җыеп алырсыз!

Хафиз. Чамалабрак сөйлә, малай! Кем белән сөйләшкәнеңне белеп сөйләш. Әгәр дә без сезнекен җыйдырсак, үзегез дә хәйран калырсыз.

Кәрим. Кем белән сөйләшкәнебезне бик яхшы беләбез, ач бет! Хәерче! *(Иярченнәренә.)* Әйдәгез, урыгыз үзләрен!

Бәргәләшүләр башлана. Дисәтникләр белән сотский керә.

Сотский. Һи, йөзегез каралар! Караңгы төн эчендә бу нинди тавыш?! Тотыгыз үзләрен!

Аеклар кача, исерекләр егылып кала. Сотский белән дисәтникләр куа китәләр.

Сиби *(кире кайтып).* Кәрим, Кәрим!

Кәрим *(кереп)*. Нәрсә? Ни бар?

Сиби. Бая мин Хафиз белән Хафизәнең сөйләшкәннәрен тыңлап тордым. Хафизә Хафизга иртәгә кич ясигыга азан әйткәндә келәтләре артына килергә кушты. Үзләрен шунда эләктерербез.

Кәрим. Ярый. Иртәгә тагы сөйләшербез. Сый миннән, тырышыгыз! *(Тиз генә китәләр.)*

Сотский белән дисәтник *(яңадан кереп)*. Әнә тегендә тагы икесе! Һи, йөзе каралар! *(Куа китәләр.)*

*Пәрдә.*

**ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Йорт артында түтәл бакчасы. Түрдә бер якта такта түбәле бер каралты. Икенче якта тәрәзәсе бакчага караган бер келәт. Келәт белән каралты арасында кечкенә капка. Вакыт кич. Ай калыккан. Яшькелт яктылыкта якындагырак кешеләрнең йөзләрен танырлык. Пәрдә күтәрелгәч, Кәрим белән Сиби шыпаеп кына керәләр. Тирә-якны тикшереп карыйлар. Кеше юклыкка ышангач, Сиби Кәримне сәхнә алдына алып килә.

Сиби. Кичә мин сиңа яхшылап сөйли алмадым. Дисәтникләр кугач, өйгә кайттым да яттым. Бүген иртә белән сиңа сөйләргә дип барган идем, син атаң белән базарга киткән икәнсең.

Кәрим. Ийе шул, вулыс эше белән этине чакыртканнар иде. Базардан әйберләр дә алып кайтасы бар иде. Базардан әле күптән түгел, яңарак кына кайттык. Мин, атны туаргач та, монда йөгердем. Йә, сөйлә, ниләр бар?

Сиби. Шул менә, мин монда бигрәк шул бар булганнарны сиңа сөйләп бирер өчен дип килдем. Кичә сез тегендә, чишмә буенда, бәетләр чыгарып маташкан арада, мин качып-посып кына ындыр артына тегеләр янына бардым да аларның ниләр сөйләгәнен, ниләр эшләгәннәрен яшеренеп кенә карап тордым.

Кәрим. Йә, йә, сөйлә, тизрәк сөйлә, нәрсәләр сөйләделәр?

Сиби. Күп артык сүз сөйләмәделәр. Хафизә безнең урам буеннан уйнап, җырлап узганыбызны, синең Хафизга ачуланып йөргәнеңне, безнең Хафизны сагалап йөрү ихтималыбыз булганын сөйләде дә, бүген кич Хафизны шушында килергә чакырды, мәзин ястүгә азан әйткәндә келәт артына, түтәл бакчасына килергә кушты. Шушында иркенләп сөйләшергә булдылар.

Кәрим. Йә?

Сиби. Бары шунда инде. Мин дә шул вакытта синең белән монда килеп, безнең яклы булган егетләр белән бергәләшеп, аларның күрешеп яткан вакытларында гына кинәттән килеп чыгып, Хафизны тотып әверергә булдык.

Кәрим. Анысын бик шәп иткәнсез, ә соң әле безнекеләр кайда?

Сиби. Мин аларга алдан ук хәбәр биреп, аларны алдан ук хәзерләп кисәтеп куйдым. Алар мунча янына, су буена килеп, шыпырт кына җыелып торырга булдылар, шунда алар тавышсыз-тынсыз гына сагалап торып, мин хәбәр биргәч тә килеп, Хафизны эләктерәчәкләр.

Кәрим. Юк, алай гына эләктерү ярамый. Бер кыйнау белән генә эш бетми. Аның яклы булган егетләр дә әз түгел. Бүген без аны кыйнасак, икенче бервакытны, вакытын туры китереп, аларның да безне кыйнау ихтималлары бар. Һәм шулай булачак та. Кичә дә без дуамалга тавыш чыгарып бәйләнүебез белән зур ялгышлык иттек.

Сиби. Соң алай булгач, синеңчә, нишләргә кирәк? Синеңчә, тик шулай гына, үзе теләгәнчә генә, рәхәтләнеп йөри бирсенмени? Минемчә, аны тотып бик нык итеп эпәләүдән башка бер юл да юк. Аны шулай итеп кенә бу тирәдән биздермәсәң, башкача һичбер төрле итеп тә биздерергә мөмкин түгел.

Кәрим. Була, башка юл белән дә бик шәп итеп эшләргә була.

Сиби. Ничек итеп?

Кәрим. Башкачарак итеп. Менә ничек: ул монда килсен дә, бик иркенләп кенә, бернидән дә шикләнмичә генә... *(Ян-ягына каранып.)* Юк, безгә монда, якын урында, сөйләшеп торырга ярамый. Кичә син анда агач артында аларны яшеренеп тыңлап торган шикелле, безне дә кемнең булса да берсенең берәр җирдә яшеренеп тыңлап тору ихтималы бар. Без хәзергә бу якын-тирәдән читкәрәк таеп торыйк әле. Безгә нишләргә кирәк икәнен мин сиңа шунда сөйләрмен.

Сиби. Белмим, нәрсә генә эшли алырсың икән, мин бер дә төшенә алмыйм. Бер дә ышана алмыйм, берәр эш чыгара алырсың микән?

Кәрим. Чыгару гына түгел, чыгарганда да менә дигән шәп итеп чыгарырбыз. Эш чыгару да, теш чыгару да алар безнең өчен берни дә тормыйлар. Әйдә, без хәзер моннан китик тә тегендә, су буенда, мунча янында иптәшләрнең җыелганын көтеп торыйк. Шуннан торып Хафизның килгәнен сагалап карап торырга да уңайлырак булыр. Шунда ук киңәш-табышларын да итәрбез.

Сиби. Әйдә алайса, киттек.

Чыгып китәләр. Сәхнәдә тынлык. Бераздан качып-посып кына Хафиз керә.

Хафиз. Ялгышмасам, тирә-яклар тыныч, беркем дә юк шикелле. *(Як-ягына карангалап, шыпаеп кына келәт янына килеп тыңлый да келәт тәрәзәсен чиертә. Эчтән җавап юк.)* Җавап юк. Ахрысы, мин ашыгыбрак, иртәрәк килгәнмендер. Билгеле, иртә килгән. Мин бит аңар мәзин ястүгә азан әйткән вакытта килермен дип вәгъдә биргән идем. Ул да шул вакытта чыгарга булган иде. Әле азан әйткәне юк. Азан әйтү түгел, әле мин килгәндә, мәчеткә ут та кермәгән иде. Йөрәк түзми шул. Тасырдап тора. Ниш-

лисең бит, тизрәк күрергә дип ашкынасың. Шул тирәдә бераз ышыкланыбрак көтеп торырга кирәк. *(Пауза.)* Бүген, әллә нишләп, эчләр пошып, күңелләр тынычсызланыбрак тора. Әллә инде кичәге тынычсызлыклар шунда баштан чыгып бетмәгәннәр. Әле ярый, минем иптәшләр күп иде. Аның өстенә тагы, бәхеткә каршы, сотскилар да килеп чыктылар. Юк исә, ихтимал, әллә нинди күңелсез хәлләр булган булыр иде. Ярый әле, үчсез котылдык, бездән дә, алардан да зарарланган кешеләр булмады. Ни җитмәгән инде шул Кәримгә! Кеше өлешенә күз төшермәсә, аңар авылда башка кызлар беткәнмени? *(Келәт тәрәзәсеннән ут яктысы күренә.)* Әһә, Хафизә келәткә чыкты. *(Тәрәзәгә чиертмәкче була.)* Юк. Ярамый. Кем белә, бәлки, Хафизә түгелдер? *(Тәрәзәдән үрелеп карый.)* Берни дә күренми. Тәрәзәнең пәрдәсен төшереп куйганнар. Азан әйткәнне көтеп тормыйча хәл юк. Күпкә түзгәнне, азга гына түзәрмен. *(Бераз читкәрәк китә.)* Тирә-якта сагалап торучылар була күрмәсен. Нигәдер күңел бик курка, тез буыннары да калтырый башладылар. *(Бер яктан азан тавышы ишетелә.)* Азан әйтә, ут та сүнми, чыгып та китмиләр, мөгаен, Хафизәдер. Тукта, сынап карыйм әле. *(Акрын гына тавыш белән җырлый.)*

Тәрәзәнең бусагасы бик киң микән, тар микән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бик киң микән, тар микән.
Хафизә күк матур ярлар бу дөньяда бар микән,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, бу дөньяда бар микән.

*(Тәрәзәдә ут сүнә дә яңадан яктыра.)* Әһә, булды, Хафизә икән. *(Барып тәрәзәне чиертә.)*

Хафизә *(эчтән)*. Хәзер чыгам. *(Утны кыса. Тынлык. Сакланып кына кечкенә капкадан чыга.)*

Хафиз. Хафизә!

Хафизә. Чү, акрын, кеше-кара күренмиме?

Хафиз *(тиз генә тирә-якны барып карап)*. Юк, юк. Беркем дә күренми, бик тыныч. *(Килә, Хафизәне коча.)*

Хафизә. Чү, тимә әле, тукта әле. Кичәге көннән бирле җаным бер дә урынында түгел әле. Нәрсәгәдер җаным тынычсызланып, борчылып тора.

Хафиз. Минем дә.

Хафизә. Кичә без киткәч ниләр булганын бер дә белә алмадым. Кешедән сорашырга да яхшысынмадым. Без китеп, Гобәйләр чатын борылгач та, аннан, сезнең яктан, ындыр артыннан әллә нинди тавыш-гаугалар ишетелде, әллә нинди сугыш-фәләннәр булмагандыр бит?

Хафиз. Юк, бик ул кадәр зур эшләр булмады. Бары тик бераз гына өстебездәге тузаннарны кагышкалап кына алдык. Шулай да, әгәр дә сотскилар килеп чыкмаган булса, шактый гына зур бәрелешүләр дә булып алган булыр иде. Үзең дә күргәнсеңдер, Кәримнең иярченнәре барысы да бик исерекләр иде. Тавыш чыгартыр өчен Кәрим аларны юри сыйлаган. Моннан соң инде алар безне бер дә тыныч тотмаслар, безгә ничек тә бераз саграк булырга туры килер.

Хафизә. Ийе шул, мин дә шулайрак дип әйтмәкче идем. Бераз тавыш-тыннар басылганчыга кадәр күрешмичәрәк, сакланыбрак торсак, ничегрәк булыр иде икән дип әйтмәкче идем?

Хафиз. Анысы шулай, мин дә шулайрак уйлыйм. Ләкин без алай торудан гына тынычлык таба алырбыз микән? Әгәр дә без һаман да шушы көйгә генә торсак, Кәрим безгә бер дә тынычлык бирмәс бит. Ул безне һаман да борчып кына торыр.

Хафизә. Соң син нишләмәкче буласың?

Хафиз. Әгәр дә мин яучы җибәреп әтиләреңнән сине соратып карасам, ничегрәк булыр иде икән? Әтиләрең сине бирергә риза булмаслар иде микән, дим?

Хафизә. Сынап кара, «ятып калганчы атып кал» дигәннәр бит, кем белә, бәлки, риза да булырлар. Ә соң әгәр дә әтиләр риза булмасалар, ул вакытта нишләрбез?

Хафиз. Риза булмыйлар икән, әгәр дә син үзең риза булсаң, ул вакытта да җае табылыр. Моннан качып китәрбез дә икенче бер авылга барып никах укытырбыз. Аннан соң калага барып, бераз вакытка кадәр калада торып торырбыз да, соңыннан, тавыш-тыннар басылгач, әтиләрең белән килешеп, яңадан авылга кайтып тора башларбыз. Аңарчы, бәлки, күз алдыннан югалып торгач, Кәримнең дә өмидләре өзелер.

Хафизә. Мин алай гына китәргә куркам шул. Әгәр дә әти-әниләр рәнҗесәләр, нишләрбез? Йә булмаса, качып киттеләр дип тоттырсалар, ни итәрбез?

Хафиз. Юк, Хафизә, син бер дә алай хафаланма, әтиләрең алар акылсыз кешеләр түгел, бер дә алай иттермәсләр. Без бит никах укытырбыз. Никах укыткан булгач, алай «качып киттеләр» дип әйтә дә, тоттыра да алмаслар. Хәзер инде андый заманнар узган. *(Як-ягына каранып.)* Минем күземә тегендә, читән буйларында кемнәрдер йөргән шикелле тоелды. Әллә нинди кеше күләгәләре күргән шикелле булдым. Безне сагалап йөрүчеләр-фәләннәр була күрмәсеннәр тагы. *(Акрын гына, шыпаең кына карый.)* Юктыр, ахры, болай гынадыр. «Курыкканга куш күренә» диләр.

Хафизә. Шулай да бит, бу бит бик читен бер эш. Баштарак, берәр төрле эшкә урнашканчы, көн күрүләре дә бик авыр булыр бит. Без бит бер дә шәһәр тормышына иялəнгән кешеләр дә түгел. Анда барып, бернисез генә ничек итеп урнашып тора башларбыз?

Хафиз. Анысы шулаен шулай да, ләкин бит шәһәр җирендә бер кешенең дә ачтан үлгәнен әйтмиләр. Шөкер әле, минем көчем дә, тазалыгым да бар. Кулымнан эш килмәслек егет тә түгел. Мин бит, бик оста булмасам да, балта эшләрен дә яхшы гына беләм. Анда берәр балта остасына ялланып эшләрмен, һич булмый икән, көнлекче булып, утын ярып йөреп булса да тамагыбызны туйдыра алырбыз әле. Шәһәр җирендә эшләгән кешегә эш табылыр. Бары тик...

Хафизә. Кара әле, тегендә минем күземә читән артыннан кешеләр үрмәләп йөргән шикелле күренә башлады.

Хафиз. Юк, берни дә юктыр. Бая миңа да шулай тоелган иде дә, ахрысы, кеше булмагандыр. Читәннең артында кемнең булса да бозаулары йөри торгандыр.

Хафизә. Юк, мин әллә нигә бик шикләнәм. Сагалап йөрүче кешеләр-фәләннәр була күрмәсен. Яхшы вакытта мин кереп китим. Йә, мине югалтып, артымнан эзли чыга башларлар. Әни әле болай да бик борчылып йөри. Озак торырга туры килмәс. Хәзергә хуш. Иртәгә тагы шушы вакытларда монда килерсең. Шунда иркенләбрәк сөйләшербез. Ничек тә саграк бул.

Хафиз. Ярый алай булса, хәзергә хуш, җаным! *(Җырлый.)*

Бакча ишегеңне ачып куй, кояш төшсен түтәлгәй,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, кояш төшсен түтәлгәй.
Күңелең, күзеңне төшермә Хафизыңнан бүтәнгәй,
Хафизәләм иркәм, аппагым ла, Хафизыңнан бүтәнгәй.

Хафизә. Хуш! *(Җырлый.)*

Кызу кояш кыздырса да бакчадагы түтәлне,
Хафизым иркәм, аппагым ла, бакчадагы түтәлне.
Хафизәң тик сине сөя, сөйми синнән бүтәнне,
Хафизым иркәм, аппагым ла, сөйми синнән бүтәнне.

Хафизәңнең бар уе син, уйнаса да, көлсә дә,
Хафизым иркәм, аппагым ла, уйнаса да, көлсә дә.
Хафизәң сине һич онытмас, үлсә, гүргә керсә дә,
Хафизым иркәм, аппагым ла, үлсә, гүргә керсә дә.
Хуш!

Хафиз. Хуш, җаным! *(Кочаклашып үбешәләр. Хафизә кереп китә.)*

Хафиз *(ялгыз. Үзалдына)*. Үзем дә белмим, ни өчендер шул Хафизә миңа авылдагы бөтен кызларның һәммәсеннән дә матуррак күренә. Үзен күргән саен күрәсе генә килеп тора. Ә күргәннән соң йөрәкләрем тибә башлый да каушавымнан сөйлисе сүзләремне дә онытып бетерәм. Берни дә сөйли алмый калам. Ах, тагын бер бик кирәкле бер сүз әйтәсем калган икән. Тукта әле, үзенә әйтим әле. *(Тәрәзәдән үрелеп.)* Хафизә, Хафизә! Ишетми. Әллә өйгә кереп китте микән? Хафизә, Хафизә!

Кәрим, Сиби һәм башка берничә егет төрлесе төрле яктан йөгерешеп керәләр.

Кәрим. Тотыгыз, тот!

Сиби. Келәт басалар!

Егетләр *(бердән)*. Тотыгыз, тот! Сибегез! Кайда сез? Келәтегезне басалар! Карак бар! Карак! *(Хафиз качмакчы була. Аны тотып алалар.)*

Кәрим һәм иптәшләре *(капканы ачып)*. Чыгыгыз! Чыгыгыз! Келәтегезне басалар!

Вахит, Хөбби кечкенә капкадан чыгалар. Тирә-яктан берән-сәрән кешеләр җыела башлый.

Вахит. Нәрсә, ни бар?

Сиби. Келәтегезне бастылар.

Хөбби. Ярабби Ходаем! Җыеп, саклап килгән бодай оным бар иде, харап булдык!

Вахит. Кайда? Кем? Кая таба китте?

Егетләр. Менә, тоттык. Кем икәнен белеп булмый. Башын яшерә.

Вахит. Кая дисәтник? Кая староста? Егетләр, зинһар, җибәрә күрмәгез, ычкындырмагыз! Кәмититкә алып барыйк.

Фазылҗан. Кабыргаларын яхшылап санагыз! *(Егетләр йодрыкларын йомарлап киләләр. Суккалыйлар.)*

Кәрим. Юк. Егетләр, монда тимәгез. Без кыйнап гаепле булмыйк. Суд үзе тикшерер.

Вахит. Ийе, ийе, егетләр, сез, зинһар, булышыгыз инде. Әйдә, кәмититкә алып барыйк үзен. Чү! Чү! Бу Хафиз түгелме соң?

Сиби. Ийе, ийе, шул икән, шул!

Вахит. Һи, яхшыдан яман туган нәрсә, оятсыз!

Хафиз. Валлаһи, Вахит абзый, минем һичбер гаебем юк. Алар бары тик дошманлык белән генә...

Кәрим. Әйдәгез, әйдә, егетләр, күп сөйләтмәгез үзен. Анда баргач тикшерерләр.
Хафиз. Кара аны, Кәрим! Онытма! Бу эш сиңа бик кыйбатка төшәр.
Кәрим. Күрербез!

Егетләр Хафизны алып китәләр.

Сиби *(Кәримне читкә тартып).* Шаулама, иптәш, эш пеште! Кыз синеке. Сыеңны гына кызганма.
Кәрим. Аннан эш калмас!

*Пәрдә.*

**ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Тәбәнәк кенә, начар гына, иске генә өй. Түрдә киң сәке, зур мич, ике якта тар гына ян сәкеләр. Сәке белән ян сәке алдында өстәл. Өстәл өстендә чынаяклар. Әби самавыр хәзерли. Старший белән иптәш солдатлары капчыкларыннан икмәкләрен чыгарып, ашарга хәзерләнәләр.

Старший. Нихәл, әби, тормышларың ничек? Көн күрүләр бик авыр түгелме? Бала-чагаларың бик күп түгелме?

Әби. Шөкер әле, бер көе генә авыш-кыеш китергәләп, гомер итеп килгән булам шунда. Минем бит бер башым да бер үзем генә. Булышырга бер кешем дә юк.

Старший. Беркемең дә юкмыни?

Әби. Балаларым булуын булган иде дә, барысы да яшьләтә үлеп беттеләр. Берүзем, берьялгызым гына калдым. Соңгы елларга кадәр карт белән икәү генә менә шулай, сезнең шикелле калага баручылар, каладан кайтучыларга аш пешереп, самавырлар куеп, двор төшергәләп көн итеп килгән идек килүен дә, узган ел картым да үлеп киткәч, бөтенләй япа-ялгыз, ятим калдым. Шулай да, шөкер әле, яхшы кешеләр бөтенләйгә үк ташлап бетермиләр. Искедән бирле аш-су күреп килгән дус-ишләр бөтенләй үк хәтерләреннән чыгарып бетермиләр әле. Узган-барганда һаман да миңа төшеп, аз-маз булса да ризыкланырлык биреп китәләр. Әллә ни артык эшләр булмаса да, тамагың тук булып, көннәрне әвеш-кыеш китерерлек булса, риза инде шунда, безнең дөньяда күп торасы калмаган инде, үлгәнче ач булып, кешедән садака-хәер сорарырга чыгарлык булмаса, бик риза инде. Шуңа риза инде. *(Пауза.)* Карагыз әле, улларым, самавыр кайнап чыгып өлгергән инде. Үземнең бер дә көчем калмаган. Билләрем дә бик авырта. Карчык кешенең карчыкларча булыр инде аның. «Картайгач, карт эт шикелле буласың» диләр иде, бик дөрес икән, бер дә карт эттән артык җирем калмаган, самавырны өстәл өстенә үзегез генә алып куймассыз микән? Бик авыр шул. Яшь чагында моннан да зур самавырларны да дыңгырдатып китереп куя торган идем.

Старший. Ярар, ярар, әби, бер дә үзегез күтәреп азапланмагыз. Безнең егетләрдә көч күп әле, алар алып куярлар. Ягез әле, иптәшләр, кайсыгыз булса да берегез самавырны алып килеп китереп куегыз әле. *(Кызылармеецлардан берсе самавырны өстәлгә куя. Чәй салып эчәргә керешәләр.)* Әби, әйдә, сез дә чәй эчәргә рәхим итегез. Утырыгыз.

Әби. Юк, рәхмәт, үзегез генә тынычлап, иркенләп кенә эчегез әле. Мин шунда, әгәр дә сездән артып калса, сездән калганны, берәрне генә эчеп алырмын. Безнең шикелле карчык кешегә чәйне күп эчү бик файдалы түгел. Тышка күп йөретә. Сез соң нинди чәй эчәсез? Яфрак чәеме? Яфрак чәй ул әллә нишләп минем йөрәгемә ярамый, йөрәгемне кисә.

Старший. Юк, әби, яфрак чәй түгел, төрле җиләкләрдән киптереп ясаган чәй.

Әби. Алай булса, берәрне генә эчеп карыйм, алайса.

Старший. Әйдә кил, рәхим ит, утыр.

Әби. Тукта инде, алай булгач, мин дә сезне сөт белән сыйлыйм. Бераз сөтем калган иде шикелле, сөтләп эчегез. *(Барып, бер савыт белән сөт китерә.)*

Старший. Алай булса, сез безне сөт белән сыйлагыз, без дә сезне шикәр белән сыйлыйк. *(Бер шакмак шикәр бирә.)*

Әби. Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт. Без инде шикәрне бик күптән үк онытып бетергән идек. *(Шикәрне ала. Ян сәкегә барып утыра, чәй эчә башлый.)* Улларым, сез соң ничек, салдат хезмәтен бетереп кайтып киләсезме? Әллә булмаса, сезне өйгә кунакка гына җибәрделәрме?

Старший. Юк, әби, без эш белән йөрибез!

Әби. Нинди эш? Әллә сезне иген-фәлән җыярга дип чыгардыларммы?

Кызылармеецлар көлешәләр.

Старший. Юк, әби, бер дә курыкма, иген җыярга түгел, башка төрле бер эш белән.

Әби. Юк, алай-болай куркып әйтүем түгел, куркырга, мин бит иген игә торган, йә булмаса, ашлык җыеп, ашлык-тару белән сату итә торган кеше дә түгел. Әле тик болай гына, исемә төшкәнлектән генә әйткән сүзем. Халык бит әлләниләр сөйли.

Старший. Алай икән. Соң, нихәл, авылыгызда нинди хәлләр бар? Авыл халкы нинди эшләр бетереп ята? Авылыгызда тынычлыкмы?

Әби. Ни эш бетерсен, безнең сала кешесенең эше билгеле инде аның. Иген игә, булса — урагын ура, көлтә кертә...

Урамда гармун тавышы һәм «Хафизәләм иркәм» көен җырлаган тавышлар ишетелә.

Старший. Алар кемнәр? Болай җырлап йөриләр? Әллә солдатка каралачак яшьләрме?

Әби. Юк, тегеләй генә, яшьләр үзара гына җырлап йөриләр. Билгеле инде, араларында салдатка каралучылары да бардыр.

Старший. Ахры, бу көй яңарак чыккан бер көйдер, минем моңарчы мондый көйне бер дә ишеткәнем юк иде.

Әби. Ийе, яңа көй ул. Монда, безнең авылда, Хафизә атлы матур бер кыз бар. Егетләрнең, яшь-җилбәзәкләрнең, беләсең инде, аларның бар белгәннәре кыз гына. «Кыз» дигәч тә кызып китәләр, аларның авызларыннан сулар килә. Яшьләрнең аларның дөньяның авырлыкларына бер дә исләре китми. Шул Хафизә дигән кызны безнең авылның ике егет сөеп йөриләр. Яшьләр шуларга төбәп бәет чыгарганнар. Әле менә бер-ике генә көн элек шул Хафиз дигән егетне келәт баскан өчен тотып яптылар. Иртәгә суд булачак.

Старший. Нинди Хафиз дигән егетне?

Әби. Шул инде, кызны сөеп йөргән егетне.

Старший. Ничек соң ул, ул шулай начар куллы егет идемыни?

Әби. Юк, моңарчы алай бер дә начар исеме ишетелгәне юк иде. Болай үзе бик акыллы, бик инсафлы егет шикелле күренәдер иде. Кеше инде карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Тышыннан гына карап, кешенең яхшымы, начармы икәнен кайдан беләсең? Кем белә, бәлки, ярлылыгыннан аптырагач, шайтан җилкеткәндер инде.

Старший. Ничек соң ул, он-фәлән, ашлык-фәлән урлаганмыни?

Әби. Юк, алай аның янында оны-фәләне булган дип әйтмиләр. Оны-фәләне булмаган, бары тик келәт тәрәзәсеннән керергә теләгән вакытта гына егетләр килеп тотканнар.

Старший. Нинди келәт тәрәзәсеннән?

Әби. Бая әйттем бит әле, Хафизә дигән бер матур кыз бар дип. Шуларның келәт тәрәзәсеннән.

Старший. Кем белә, бәлки, ул анда урлар өчен кермәгәндер, кыз янына килгәндер.

Әби. Ул кадәресе инде безгә караңгы. Бәлки, шулайдыр. Иртәгә судлары булачак. Шунда беленер әле. Ләкин тоткан егетләр келәт басарга кергән иде, дип әйтәләр икән.

Старший. Аны соң кемнәр тоткан?

Әби. Шулар инде, бая әйткән идем бит әле, кызның икенче бер сөйгән егете бар дип, шул егетләр тоттырган. Әле ул бүген кич монда безгә килеп, иптәш егетләрен җыеп сыйламакчы булып киткән иде. Бәлки, озакламыйча килеп тә җитәрләр инде. Миңа ашарга да әзерләп куярга кушып киткән иде. Ике каз да пешертте. Кайдандыр ике чиләк бал да алып килделәр. Базга төшереп куйдым, озакламаслар, бәлки, килеп тә җитәрләр инде.

Старший. Алай икән! Әби, син «каз» дигәч искә төште. Синдә бераз ашарлык берәр нәрсә юкмы? Без сиңа бәясен түләрбез. Үзеңдә булмаса, башка берәр кешедән булса да табып китерә алмассыңмы? Маймы, йомыркамы, кайсы булса да ярый. Ит булса, бигрәк тә яхшы. Мә, менә, акчасын да ала кит, камисар кайткач, аңарга да ашарга нәрсә кирәк булыр.

Әби. Үземдә сезгә җитәрлек нәрсә табылмас шул. Ярый, күрше-коланнарга барып карыйм. Табарга тырышып карармын. Бәлки, табылыр әле. Ә соң үзегез генә чыгып эзләп керә алмассыз микән? Мин бит ялгыз кеше.

Старший. Әби, курыкма, без синең әйберләреңә тия торган кешеләр түгел, әгәр дә син үзең генә барырга курыксаң *(бер кызылармеецны күрсәтеп)*, менә бу иптәш тә синең белән барсын. Без бит солдат кешеләр. Солдат кеше авыл халкының күзенә күренеп, әйбер сорый башласа, бушлай алмагайлары дип куркып, сатарга теләмиләр, бары тик шуның өчен генә сезгә кушам.

Әби. Әйдә, ярый алай булса, күршеләрдән берәрсенә барып карыйк. Бәлки, бирерләр.

Старший *(иптәшләреннән берсенә)*. Бар, Шакир иптәш, әби белән син барып кил әле. Менә сиңа бераз акча, барыгыз, тизрәк кайтыгыз!

Шакир. Слушаюсь!

Әби. Ярый, барып карыйк, әйдә алайса, улым, барып карыйк. Һи, язмыш! Әгәр дә исән булсалар, минем дә сезнең шикелле балаларым булыр иде.

Шакир. Әйдә, әби, киттек.

Әби. Әйдә, бәбкәем, әйдә. *(Чыгалар.)*

Старший. Кызык эшләр! Бу әбинең сөйләгән әкиятләре мине бик гаҗәпләндерә башладылар әле. Бу эштә нинди булса да берәр төрле сер булырга кирәк, минем шул серне аңлыйсым килә. Мин монда мич башына менеп, яшеренеп ятам. Ә сез, әби кайткач, нинди булса да берәр төрле сылтау табып чыгып ки-

тегез. Соңыннан, егетләр киткәч, кайтып ятырсыз. Йә булмаса, туп-туры ишегалдында арбага ятырсыз, бүген көн җылы, туңарлык түгел. Әби кайткач мине сораса, «йөреп керәм» дип чыгып китте диярсез. Аның ул егетләрне сыйлауның нинди булса да берәр төрле мәгънәсе булырга кирәк, ул аларны бушка гына сыйламый торгандыр, аңладыгызмы, иптәшләр? Әгәр дә андый-мондый зуррак эш чыкса, камисар кайткач, аңар да белдерербез. Аңладыгызмы?

Кызылармеецлар. Аңладык.

Старший. Ярый, әйдәгез эшкә. *(Мич башына менәп ята.)*

Бер кызылармеец. Чыннан да, моннан берәр төрле эш чыгу ихтималы бар бит, ә? Кем белә, бәлки, алар арасында дезиртирләр дә бардыр әле.

Икенче кызылармеец. Билгеле, бардыр.

Карчык белән кызылармеец керәләр.

Әби. Ну, егетләр, бәхетегез бар икән. Мин бер дә табылыр дип уйламаган идем, сез сораганнарның барысы да табылды.

Бер кызылармеец. Рәхмәт сиңа, әби, ярый, бик яхшы булган, алайса. Әби, хәзергә син ул нәрсәләрне беразга җыеп куеп тор. Старший кайткач, үзебез сорап алырбыз. Бәлки, ул тиз кайтмас.

Әби. Ул, старшина дисезме, кайда китте соң ул әле?

Бер кызылармеец. Ул «бераз йөреп керәм» дип чыгып китте. Камисар эш белән киткән иде, алар, бәлки, бүген бөтенләй дә кайтмаслар. Тиз кайтмасалар, без йоклап-нитеп калсак, кайткач сорасалар, алып бирерсең. Шакир иптәш, синең йокың киләме, минем йокым бик килә, мин тышка арбага чыгып старшийлар кайтканчы бераз йоклап алмакчы булам, синең йоклыйсың килмиме?

Шакир. Килмәгән кая ул, бик килә, бик арылган.

Бер кызылармеец. Әйдә алай булса, арбага чыгып бераз йоклап алыйк. Әйберләрне дә үзебез белән алыйк. Кәзүнни нәрсәләрне калдырып йөрү ярамас. *(Шыпыртлап.)* Теге егетләр килгәч, күреп шикләнмәсеннәр. *(Ымлый да барысы да чыгалар.)*

Әби. Барыгыз, бар, балаларым, ял итегез, аргансыздыр. Ерак җирдән килгәч армый ни. *(Үзалдына.)* Юньле генә егетләргә охшыйлар. Шулай да алар сораган нәрсәләрнең барысы да үземдә бар икәнен әйтергә курыктым. Кем белә бит, бәлки, әллә нинди кешеләрдер. Очраган бер кешегә ышанып бетереп булмый. *(Урамда җыр, гармун тавышлары ишетелә.)* Киләләр бугай, ярый, бик яхшы, бик вакытлы киләләр. Салдатлар бар вакытта килүләрен бер дә күңелем тартмаган иде. Ярый әле чыгып киттеләр. Башка кешеләр булса, мин аларны фатирга да төшермәгән булыр идем дә шул, салдат кешегә сүз әйтеп булмый. Әллә нинди бәлагә эләгү ихтималың бар.

Кәрим керә.

Кәрим *(сузып, сыер мөгрәгән аваз белән болагайланып)*. Әби өйдәмү?!

Әби. Өйдә, өйдә, балакайларым, әйдәгез, рәхим итегез, хуш киләсез.

Кәрим *(ишекне ачып)*. Әйдәгез, егетләр! *(Алты-җиде егет керә, кайсы исерек, кайсы кызмача.)*

Әухәди *(кереп)*. Ха, ха, ха, ха! Шәп эш, ә?! Сыйланабыз диген, ә? Кәрим шәп егет ул, ярый ул, аның өчен, ичмасам, нишләсәң дә стует. Ә ул Хафиз нәрсә? Ул бит ач бет! Аның үзенә дә юк, кешегә дә.

Кәрим *(кызмача)*. Ну, егетләр, әйдәгез, сәке түреннән. *(Утыралар.)* Әйдә, тарт гармуныңны!

Гармунчы. Була ул. Хафизә көенме?

Кәрим. Ярый, тарттыр. Әй, юк, кирәкми, бүгенгә аны тарттырма, башканы әйттер.

Фазылҗан. Хафизә көен аны Кәрим Хафизәне алган вакытта туйда әйттерербез.

Кәрим. Әби, кая, баягы казлар белән балларны китер әле.

Әби. Ярый, хәзер китерәм. Мин аларны, бик әчеп, тәмсезләнеп, кыркуланып бетмәсен дип, базга төшереп куйган идем. Хәзер алып менәм.

Кәрим. Ярый, бар алайса, тизрәк алып мен.

Әби. Ярый, хәзер. *(Чыга.)*

Кәрим. Ягез, әйдәгез, әйттерә башлагыз. Тарт гармуныңның колагын!

Гармун уйный, егетләр җырлыйлар. Бу урында нинди булса да берәр төрле авыл көе җырлана.

Фазылҗан. Шуны беләсе иде, тегендә Хафиз нишләп ята икән, Хафиз? Кандалалар белән борчалар үзен үрле-кырлы сикертәләр бугай.

Фатыйх. Әле аның сикерәсе көннәре алда. Аны судта тагы да яхшырак сикертерләр әле. Ну, малай, Кәрим, үзеңдә баш та бар икән соң! Кайдан табып уйлап чыгарган бит! Келәт басарга кергән, имеш! Ха, ха, ха, ха! Келәт басарга диген, ә? Ийе, келәт басарга кергән. Тычкан кимерерлек бер сынык каткан икмәгә дә булмаган буш келәтне басарга! Ха, ха, ха, ха!

Кәрим. Йә, җитәр инде. Авызыңны бик артык җырма. Беләсең икән — бик яхшы, эчеңнән генә тын. Йә әби килеп керер.

Фатыйх. Мин бит болай гына, үземнең исем киткәннән генә әйтәм. Келәт баскан диген, ә? Ну соң үзендә баш та бар икән! Һаман әле көләсем килә. Ха, ха, ха, ха! Хафиз келәт баскан?

Фазылҗан. Йә, сиңа әйтәләр бит инде «тик утыр» дип. Бу кадәр тотнаксыз бортак авыз булырсың икән!

Фатыйх. Юк, юк, мин бит болай гына. Әйдә уйна гармуныңны, мин биим.

Гармунчы озын көй уйный. Фатыйх алпан-тилпән биеп маташа. Әби бер култык астына каз кыстырып, ике кулына ике чиләк белән бал күтәреп керә.

Давыт. Менә, ичмасам, әбине мактасаң да ярый. Әби дисәң дә әби. Әбинең дә менә дигәне! Җан теләгән нәрсәне алып килгән бит.

Әби. Караңгыда базга чүт-чүт кенә егылып төшмәдем. Егетләре яхшы, егетләре! Егетләр хөрмәтенә генә төштем. Юк исә караңгы төн уртасында җен оясы — базга һич аягымны да атлап төшмәс идем. Төнлә белән базга күп төшеп йөрергә ярамый. Җен сирпелүе бар.

Кәрим. Рәхмәт сиңа, әби, рәхмәт. Синең яхшылыгыңны һичбер вакытта да онытмабыз. Менә эшләр генә бетсен, әби, аннан соң мин сине буш итмәм, әби. Үзең дә беләсең бит әле, безнең эшләр бар. Менә кайчан Хафизә минеке булыр, шул вакытта мин сине түр башына менгереп утыртып, баш кодача итеп сыйлармын.

Әби. Бик яхшы, улым, бик рәхмәт. Алла морадларына ирештерсен. Чибәр егетләргә чибәр кызлар килешә. *(Читкә.)* Атаң үлсә ни миңа, анаң үлсә ни миңа. Биш сум акчаң бир миңа.

Фатыйх. Торам, торам да, һаман да минем исем китә, Хафиз тегендә, ябылган җирендә, ниләр генә уйлап ята икән? «Чыннан да әллә мин келәт басарга кирәдер идемме икән» ди микән? Ха, ха, ха, ха!

Давыт. Фу, валлаһи! Тәмам туйдырып бетердең инде син дә. Әйдә, тот кулыңа да эч. Эчеп исерерсең дә кайтып йокларсың.

Фатыйх. Юк әле, тора тор әле, мин бер дә исерек түгел! Ха, ха, ха, ха! Минем бары тик көләсем генә килә. Хафиз-егет келәт баскан. Аның дала-кыр шикелле такыр идәненә сөртенеп егылып башын ярган! Ха, ха, ха, ха!

Давыт. Булса соң, сиңа нәрсәгә? Син тик эчүеңне генә бел. Сез дә шул, сезгә нигә кирәк иде шул бортак авызны ияртеп йөрергә!

Фатыйх. Исерек! Итәрсең мине тиз генә исерек! Әйдә менә уйнап кара бию көен, мин сиңа биеп күрсәтим. *(Торып биемәкче була да абынып егыла.)*

Давыт. Йә, тор инде, нәрсә ауныйсың?

Кәрим. Йә, тимәгез аңар, ятсын шунда. Аның булуы җиткән инде. Әйдәгез, егетләр, ашагыз, эчегез, уйнагыз, көлегез, биегез, бүген минем туй!

Фатыйх *(яткан җиреннән)*. Юк әле... Туй түгел... Туй алда... Кәрим, мине туйдан калдырма... *(Йокыга китә.)*

Давыт. Ягез әле, тагы бераз җиңел көйләрдән әйттереп җибәрегез әле.

Эчәләр, җиңел уйнала. Җырлыйлыар, биилә́р, исерәләр.

Кәрим. Ягез, иптәшләр, күңелегез булдымы инде?

Егетләр. Шәп, шәп, бик шәп! Маладис, Кәрим, маладис! Кәрим маладис! Кәрим барысын да булдыра ул!

Кәрим. Туктагыз әле, егетләр, монда бал бик күп бит әле. Әйдәгез, эчәбез.

Әби. Егетләр, бераз саграк булыгыз. Бик тавышланмагыз. Монда каладан килгән фатир төшкән салдатлар бар. Араларыннан берсе зуррак башлыклары булырга кирәк, ансы йөрергә чыгып китте. Шулар ишетә күрмәсеннәр, яхшы түгел...

Егетләр. Нәрсә? Салдатлар? Кайда? Нинди салдатлар?

Әби. Нindиләр икәнен белмим, башлыклары йөреп кайтам дип чыгып китте. Аннан да зуррагы, камисар дигәне, вулыска кантурга киткән бугай. Башкалары ишегалдында, арбада йоклыйлар.

Егетләр *(аерым-аерым)*. Ват тибә на! Менә сына кирәк булса.

Фазылҗан. Менә сиңа пәрәмәч!

Давыт. Бетте баш алай булса! Әйдә, үкчәң күтәр, сыз тизрәк!

Кәрим. Син нишләп соң аны элегрәк әйтмәдең?

Әби. Әйтәм бит, тышта, арбада йоклыйлар дип, бик тавышланмасагыз, алай бик күп зарарлары булмас.

Кәрим. Юк инде, алай булгач, барып чыкмады. Әйдәгез, егетләр, киттек моннан!

Давыт. Туктагыз әле, эчеп бетермәгән бит.

Кәрим. Юк, ярамый, монда ярамый. Әйдәгез, балның бер чиләген үзегез белән алыгыз. Калганын иртәгә яңадан килеп эчәрбез.

Давыт. Ну, ярый алайса, әйдәгез!

Кузгалалар, алпан-тилпән килеп чыгалар. Фатыйхны уятып, җитәкләп алып чыгалар. Урамда җыр, гармун тавышлары ишетелә. Әби өстәлне җыештыра.

Әби. Ахры, башка җирдә күбрәк эчкәннәрдер. Бер чиләкне дә эчеп бетерә алмадылар.

Кызылармеецлар керәләр.

Шакир. Тышта шактый гына салкынча икән, өрә башлады. Инде кунаклар киткәч, керергә дә ярый торгандыр.

Әби. Ярый, ярый, бик ярый. Әйдә, сез дә бераз кунак булыгыз. Менә, каз итләреннән, балдан да рәхим итегез. *(Алларына каз ите куя. Берәр җамыяк бал салып бирә.)* Монысын базга төшереп куйыйм әле. Монда торып кыркуланып бетмәсен. Иртәгә тагын килеп, баш төзәтергә дип сорарлар әле. *(Чыга.)*

Старший *(мич башыннан төшеп)*. Иптәшләр, безгә монда эшләргә шактый гына зур эшләр бар икән әле. Камисар кайткач, мин эшне аңар далажит итәрмен. Ул аларның күрмәгәннәрен күрсәтсен, арт сабакларын укытсын әле.

*Пәрдә.*

**ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Нигъмәтләрнең өе. Авылча чибәр генә җыештырылган. Хатирә өстәлгә аш урыннары хәзерләп йөри. Өстәл янына тыштан урындыклар кертә.

Хатирә *(әзерләп бетереп)*. Инде шәп булгандыр. Аш-сулар гына булып җитсә, килсәләр дә ярый. Менә кызык. Кәрим Хафизәне алам, Хафизның башын чыкмас тишеккә тыгам, дип йөргәндә генә, үзе эләккән дә куйган. И, абый шатланган! Шатлыгыннан бөтенләй эченә дә сыя алмый: Кәрим-кәрләләргә аларга хәзер инде кришке диме, книшке диме шунда, ансы ни дигән сүздер инде. Ярый инде, бәхетләре бар икән. Мин бер дә болай булыр дип уйламаган идем. Түбән очлар Хафизның башын чыкмас тишеккә тыга алмаганнар шул. Ярый, бик яхшы, шулай кирәк аларга, борыннарын бик югары чөеп йөриләр иде, менә хәзер чөеп карасыннар инде, хәзер сыйларга Кәримнәре юк. Тукта, җиңги янына чыгып керим әле, ул әзерләнеп җитә микән? *(Чыга. Пауза.)*

Нигъмәт *(ишектән Әхми белән кереп)*. Ну, Әхми иптәш, әйдә рәхим ит, моннан элек Хафизга яла яккан чакларда Кәримнәр бәйрәм иткән булсалар, хәзер инде без бәйрәм итәбез. Безнең шикелле ярлыларның сыйлары зур булмаса да, дошманнарны җиңүнең шатлыклары зур булыр.

Әхми. Мин судка бара алмадым бит, суд ничек булды соң?

Нигъмәт. Анда, туган, эшләр башкачарак йөри икән. Анда син Кәмитит Сиражи малае дип исләре китеп тормыйлар икән. Монда беренче җавапны алган чагында гайрәт орган малайларын, анда баргач, бөтенләй песи булдылар да калдылар.

Әхми. Йә, йә, сөйлә әле, эшләр ничек булды?

Нигъмәт. Тукта әле, мин кат-кат сөйләргә катыннар түгел, менә иптәшләр килсеннәр, аннан соң барыгызга бердән аермачык итеп сөйләп бирермен. Мин сөйләп бирә алмаганнарын Хафиз белән Хафизәдән сөйләтерсез. *(Ишекне ачып.)* Хатирә!

Хатирә *(ишектән кереп)*. Нәрсә, абый?

Нигъмәт. Йә, сез ничек, әзерләнеп җитәсезме инде? Хафизәләр тиздән кайтып та җитәрләр инде.

Хатирә. Без хәзер, җиңги әйтә: «Муллалар белән кодалар килеп җитсә дә ярый инде, — ди. — Безнең барысы да хәзер инде», — ди.

Нигъмәт. Нинди кодалар? Нинди муллалар?

Хатирә. Ник, никах укырга. Туй итәргә.

Нигъмәт. Аларның никахлары укылгандыр инде. Без бит монда кызыл туй итәбез.

Хатирә. Әбәү! Ул нинди туй була соң ул тагы? Абый, аның туйның кызыллары, яшелләре дә буламыни?

Нигъмәт, Әхми көләләр.

Нигъмәт. Була шул, сеңелем, була. Бик кызык, бик күңелле була. Менә килгәч күрерсең әле.

Хатирә. Әкәмәт икән, алайса.

Нигъмәт. Әкәмәт шул. Менә синең үзеңне дә шундый кызыл туйлар ясап кияүгә бирербез әле.

Хатирә *(оялып)*. Әй, китсәнә, мәхәббәтсез! *(Чыга.)*

Әхми. Яшь әле ул, йә, шуннан соң?

Нигъмәт. Нәрсә шуннан соң?

Әхми. Судта эшләр ничек булды, дим.

Нигъмәт. Андагы әкәмәтләрне сөйли-сөйли арып бетәрсең, әйттем бит инде, егетләр, кызлар килсеннәр дә аннан соң барыгызга да берьюлы сөйләрмен дип. *(Тышта, еракта җыр, гармун.)* Әнә егетләр дә киләләр бугай, әйдә, үзләрен каршы алыйк.

Әхми. Әйдә. *(Чыгалар. Пауза.)*

Хатирә *(кереп)*. Әбәү, абыйлар чыгып та киткәннәр икән әле. Урамда әллә кемнәр җырлап киләләр. Әллә кызыл туй дигәннәре шул микән. Мөгаен әле, кызыл әләмнәр дә күтәреп килә торганнардыр. Шуңа күрә кызыл туй ди торганнардыр. *(Җыр тавышы якынлаша.)*

Җыр:

Көн авыша, төн авыша,
Безнең яшьләр кавыша;
Сөйгәненә каушалмаган
Авыруга сабыша.

Матур егет, матур кызлар
Бер-берсен табыша;
Бездә хаклык, бөтен яшьләр
Безнең якка авыша.

Хатирә *(тәрәзәдән карап)*. Шул, шул, әйттем бит кызыл әләмнәр күтәреп килә торганнардыр әле дип. Менә хәзер белдем инде кызыл туйның нәрсә икәнен! *(Йөгереп чыга.)*

Җыр:

Кәрим туе карчыкта,
Үзе ята капчыкта;
Иптәшләрең күп бит синең,
Әйдә сыйлан, бар, чык та.
Кәрим эше шәп ие,
Бар иде аның әбие;
Тәбегә төшкән тычкан кебек,
Капчык эчендә бие!
Шәп, ди, Кәримнең өе,
Сау торамсың бер көе;
Бу кем көе дип сорасаң,
Кәрлә Кәримнең көе!

Хатирә *(йөгереп кереп)*. Җиңги, җиңги, киләләр, киләләр! Әй күңелле дә соң!

Нигъмәт. Әйдәгез, әйдә, кодалар, хуш киләсез!

Әхми. Әйдәгез, егетләр, әйдә, түрдән узыгыз!

Кәли *(кереп)*. Кызыл туйлар мөбарәк булсын, яшьләр башына бәхет кунсын, өйләре бала белән тулсын. *(Көлешәләр.)*

Әхми. Һи, тозсыз! Теләк тә тели белмисең, алар мәчемени өйне бала белән тутырырга?

Кәли. Башка нинди теләк телим соң? Шуннан артыгы безнең кулдан килми инде. Бай булсыннар дип әйтә алмыйм, буржуйлардан болай да бик күп җык күргән инде.

Нигъмәт. Ягез, әйдә утырышыгыз, гәпләшегез! Тиздән кияү белән кыз да кайтып җитәрләр инде.

Бер егет. Алар соң нигә кайтмый калдылар?

Нигъмәт. Никах укытырга калдылар, мин туйга әзерләнә торырга дип алданрак кайттым.

Кәли. Анда нинди никах ул тагы?

Нигъмәт. Нинди никах булсын, кызыл никах. Берсе алганлык, икенчесе барганлык хакында язылырга калдылар.

Кәли. Ә, алай икән, бөтенләй аңлый яздым.

Әхми. Йә, Нигъмәт, бая әйткәнеңне сөйлә инде?

Егетләр. Нәрсәне, нәрсәне?

Нигъмәт. Судның ничек булганын. Әхми бая миннән судтаниләр булганын сораган иде дә, мин, кат-кат сөйләмәс өчен, сез килгәч сөйләргә дип калдырган идем.

Егетләр. Чынлап, сөйлә әле, без дә ишетик.

Нигъмәт. Суд бөтенләй бер кәмиткә әйләнеп китте. Кәримнең иярченнәре берсе өстенә берсе сөйләп, бутап бетереп, адәм көлкесе булып беттеләр. Берсе әйтә: «Хафиз келәткә керде», — ди. Икенчесе әйтә: «Кермәде, бары керергә генә маташадыр иде», — ди. Берсе: «Хафизны кыйнадылар», — ди. Икенчесе: «Кыйнамадылар», — ди. Сез мунча янына ни өчен килгән идегез, дигәч, берсе: «Кәҗә эзләргә килдем», — ди. Икенчесе: «Кәрим килергә кушты», — ди. Шулай да әгәр дә судта Хафизә белән старше дигән салдат булмаган булса, Хафизның эше начар булган булыр иде. Ну соң Хафизә белән старше дигән салдат бөтен серне ачтылар да салдылар. Салдат Кәримнәрнең әби йортында ниләр кы-

ланганнарын,ниләр сөйләгәннәрен — һәммәсен дә бәйнә-бәйнә ачты да салды да бирде. Ул старше, алар әбигә килер алдыннан Кәримнәрнең әбигә киләчәкләрен ишеткәч, мич башына менеп ятып, кемнең нәрсә сөйләгәнен тыңлап яткан икән. Ә тегеләр, исерек баштан мактанышып, үзләренең нәрсәләр эшләгәннәрен һәммәсен дә сөйләгәннәр. Салдат шуларның һәммәсен ап-ачык сөйләде дә бирде. Судтагы бөтен халык түзә алмыйча яңгыратып кул чаптылар. Ә аннан соң инде Хафизә дә эшне ап-ачык итеп сөйләп биргәч, Кәрим иярченнәренең корган төрле пәрәвез оялары себерелеп түгелде. Кәрим яклы булып ялган шаһитлык биргән иярченнәрнең йөзләре күп-күнгәк булып, тораташ булып каттылар.

Нигъмәт сөйләгәндә, кызлар, берәм-берәм кереп, аш өенә таба узалар.

Егетләр. Ә соң Хафизә нәрсә дип сөйләде?

Нигъмәт. Хафизә ул бөтенләй халыкның исен китәрде. Мин, диде, авылда җавап алган вакытта, диде, авыл хатыннарының миңа төрле яла ябуларыннан куркып, диде, дөресен сөйләргә курыккан идем, диде, соңыннан Хафизны караклыкта гаепләп япканнарын күргәч, җавап алган вакытта Кәрим иярченнәренең Хафизга ялган яла ягуларын ишеткәч, минем аркамда аның хурлыкка калачагын белгәч, һич чыдый алмадым, бөтен куркуларымны, оятларымны бер якка ташладым да, дөресен сөйләр өчен, батыраеп, монда судка килдем; Хафизны келәт янына мин чакырдым, аны анда мин китердем, Хафизның һичбер келәт басканы да юк, һичбер нәрсә урларга уйлаганы да юк, болар бары Кәрим иярченнәренең уйлап чыгарган ялганнары гына, диде. *(Бөтен егетләр яңгыратып кул чабалар.)*

Егетләр. Маладис Хафизә, маладис! Ну соң кыз да икән! Йә, йә, шуннан соң?

Нигъмәт. Шуннан соң Кәрим иярченнәре күп-күнгәк булдылар да калдылар, телләре тотлыкты.

Егетләр. Шуннан соң, шуннан соң?

Нигъмәт. Шуннан соң судиәләр киңәшкә кереп киттеләр дә, бераздан чыгып, Хафизның акланганлыгын, Кәрим иярченнәренең ялган таныклык биргәнлекләре өчен судка биреләчәкләрен әйтеп, ябарга алып киттеләр. *(Егетләр кул чабалар.)*

Егетләр. Йә, йә?

Нигъмәт. Ә аннан соң тагы шул да бар икән әле, судка килүчеләрнең дакументларын тикшергән вакытта Кәримнең дизиртир икәнлеге беленгәнлектән, аны дизиртирләрне яба торган төрмәгә алып киттеләр. Аннан соң Хафизны коткарып чыгарып җибәрделәр.

Егетләр. Шуннан соң?

Нигъмәт. Аннан соң судка җыелган яшьләр Хафиз белән Хафизәне тәбрикләп, Хафизны чөеп, аларны сыйларга алып китмәкче булдылар. Без моннан баручылар аңа ирек бирмәдек, егетләр: «Без авылга алып кайтып, аларның туйларын итәбез», — ди башладылар. Шуннан ук үзара акча салышып, авылга алып кайтырга, сыйлар алырга булдылар. Авылга кайткач, йә яңадан берәр төрле комачаулык чыгар да яңадан аркылы төшүчеләр булыр дип, Хафиз белән Хафизәне күндереп, язылышырга алып киттеләр, мине туйга әзерләнә торыр өчен монда кайтарып җибәрделәр. *(Тышта кыңгырау тавышлары.)* Инде тиздән кайтып та җитәрләр, яңлышмасам, бу кыңгырау тавышы шуларныкы булырга кирәк.

Егетләр *(ду кубып)*. Шулар, шулар! Әйдә, каршы алырга! *(Чыга башлыйлар.)*

Арадан берәү. Җырлап каршы алабыз, җырлап!

Тавыш. Әйдәгез, егетләр, җырлап!

Чыгалар. Икенче яктан кызлар да йөгерешеп чыгалар. Тышта җыр.
Жиңгел көйгә җырлана.

Хуш, хуш килегез, бакча булсын илегез, *(2 тапкыр.)*
Ике матур килгән юлга гөлчәчәкләр сибегез. *(2 тапкыр.)*
Сип, сип, сибегез юлларына гөлчәчәк, *(2 тапкыр.)*
Чәчәк күк үк матур булып яшьләр гомер итәчәк. *(2 тапкыр.)*

Атлар килеп туктаган тавыш, күтәренке рухлы тавышлар.

Килде, килде яшь бикәч, әйдә тизрәк ишек ач.
Өйләргә дә ямьнәр керсен, яшь бикәчләрне күргәч.

Нигъмәт *(ишектән кереп, юл биреп)*. Хуш килдегез, рәхим итегез, яшь кияү, яшь бикәч!

Җиңги *(эчтән йөгереп чыгып каршы алып)*. Хуш киләсең, килен, төкле аякларың белән, бәхетең белән. *(Ишектән тупырдашып керәләр.)* Әйдә, килен, әйдә, кияү, түрдән узыгыз. *(Мендәрләр салган ике урындыкны күрсәтә.)*

Хафизә.
Хафиз. Рәхмәт, җиңги, илтифатыгызга.

Егетләр, кызлар тирә-яктагы эскәмиәләргә тезелеп утыралар.

Җиңги. Әткәгез белән әнкәгезгә дә хәбәр иттем. Алар да хәзер киләләр. Хафизның котылганын ишетеп алар да бик шатландылар.

Хафизә. Рәхмәт.

Җиңги. Картайганнар шул инде. Аларның да ахыр гомерләрендә дөньяда тынычлап торасылары килә. Ярый инде. Шатлык, тигезлек белән гомер итегез.

Нигъмәт *(поднос белән өч стакан бал китереп өстәлгә куеп, икесен Хафиз белән Хафизәгә биреп)*. Мәгез, юлда озак кайтып тамакларыгыз кипкәндер, балдан рәхим итегез, менә сезгә май. Майдан да авыз итегез. Дөньяда балдай татлы, майдай тук булып гомер итегез. *(Өченче стаканны кулына алып.)* Иптәшләр, мин сезгә бер-ике генә сүз сөйләп, үземнең шатлыгымны белдермәкче булам. Иң элек якын күргән иптәшем Хафиз белән аны тиң күреп, аңа иптәш булган Хафизәне никадәр зур авырлыклар күреп, никадәр зур хурлыкларга чыдап, ахры бер көн җиңеп, кавышулары белән тәбрик итәм. Бу җиңү бер Хафиз белән Хафизәнең җиңүе генә түгел, бәлки, бик күп ярлыларның байгураларны җиңүе, төрле пәрдәләр астында тоткынлыкта яткан туташларыбызның, авыр пәрдәләрне ертып ташлап, якты дөньяга чыгу җиңүе. Яшәсен меңнәрчә Хафизәләр! Яшәсен меңнәрчә Хафизлар, ура!

Егетләр. Ура! Яшәсен Хафизә! Яшәсен Хафиз!

Хафиз *(торып)*. Нигъмәт иптәш бик дөрес сүз әйтте. Чыннан да, без моңарчы тоткынлыкта идек. Әгәр дә без үзебез тоткынлыгыбызны аңлап, бергәләшеп баш күтәреп чыкмасак, бәлки, без тагын да ничә елларга кадәр шул тоткынлыкта яшәгән булыр идек. Ривәлүтсия килеп, безнең аякларыбыздагы богауларны өзде. Без богаудан котылдык. Безнең богаудан котылуыбыз ачуыннан байлар безгә каршы тешләрен шыкырдаталар. Шыкырдатыгыз, иреннәрегезне чәйнәгез, без барыбер сезне җиңәрбез! Мин бу стакандагы ширбәтне үзебезнең җиңүебез, минем һәм минем кадерле иптәшем Хафизә һәм сез иптәшләрем хөрмәтенә эчәм. Барыбызның да киләчәк тормышларыбыз татлы булсын! *(Стаканын Хафизә стаканына чүки. Икесе бергә эчәләр.)*

Һәммәсе. Яшәсен Хафиз, яшәсен Хафизә!

Карт керә.

Карт *(ишектән кереп)*. Әссәламегаләйкем!

Егетләр. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, бабай, хуш киләсең!

Карт. Киләм, балаларым, киләм, бик шатланып киләм. Хафизның котылганын, Хафизә белән кушылганнарын ишетеп, аларны котларга дип киләм. Туйларыгыз котлы булсын. Хафиз улым, Хафизә, син дә, бик исән-сау, шатлык белән йөреп кайттыгызмы?

Хафиз. Хәйри бабай, сезнең яхшы теләкләрегез аркасында, бик исән-сау кайттык. Әйдә, бабай, түрдән узыгыз, безнең сөекле кодаларыбыздан булырсыз.

Карт. Узам, балаларым, бик шатланып узам. Үзем дә шул сезнең шатлыкларыгызны күреп, карт көнемдә бер яшәреп калыйм дип килдем. Сезнең хәбәрләрне ишетеп, бөтен авыл шау килә. Әле монда килгәндә, мәчет яныннан узганда, мәзингә очрадым, миңа әйтә: «Болай ашыгып-ашыгып кая барасың?» — ди. Мин әйтәм: «Хафиз белән Хафизәнең туйларын күрергә барам», — дим. Миңа әйтә: «Һи син, карт җүләр, — ди, — картайган көнеңдә син дә шул җүләрләр белән бергә җүләрләнеп йөрисеңме инде, — ди. Үзеңнең бер аягың җирдә, икенче аягың гүрдә, картайган көнеңдә сиңа мәчет түрендә генә утырырга кирәк иде, — ди. Андый шайтан бала очырган җиргә баручыларга, андый шайтаннарга ияручеләргә хәзрәтнең дә бер дә ризалыгы юк», — ди. Мин әйттем: «Хәерле булсын, мин әйтәм, ризалыгы булмаса булмас инде, мин әйттем. Моңарчы да аларның ризалыкларын алабыз дип кара җәяүгә калып беттек инде», — дидем. Шуннан соң мәзин ачуланып кулын селтәде дә китте.

Хафиз. Бик яхшы иткәнсең, бабай.

Нигъмәт. Рәхмәт, бик яхшы иткәнсең, бабай.

Карт. Шулай булмый ни, моңарчы нинди-нинди генә туйлар булмады, ярлы булгач, берсе дә, син карт кеше, әйдә туйга рәхим ит дип, безнең шикелле ярлыларны чакыручылар булмады. Муллалары да, мәзиннәре дә — барысы да байлар белән генә булып килделәр. Ә менә сез, чакырмыйча гына килсәм дә, ике куллап каршы алдыгыз! Рәхмәт сезгә, балаларым, шатлык белән тигез гомер итегез!

Хафиз. Рәхмәт, бабай, безне тиң күрүегезгә. Нигъмәт иптәш, бал-майдан Хәйри бабайга да авыз иттер әле.

Нигъмәт. Була ул. *(Бал салып бирә.)*

Карт *(балны алып)*. Без яшь чакта балны аны җырлап бирә торганнар иде, хәзер сезнең яшьләрдә андый йолалар юкмыни?

Нигъмәт. Нишләп булмасын. Бик бар. Әйдәгез, иптәшләр, Хәйри бабайга җырлап та бирегез инде.

Әхми. Әйдәгез, егетләр, җырлыйбыз.

Егетләр. Әйдәгез. *(Җырлыйлар.)*

Әйдә, дуслар, җырлап бирик,
Китерик туйның йоласын;
Безнең дуслар шат булсыннар,
Дошманнар тик еласын.

Көн-төн баю, ярлы талау —

Дошманнарның уйлары;
Дуслар белән бергә булсын
Без ярлының туйлары.

Безнең авыл зур авыл,
Уртасыннан су ага;
Элек байлар рәхәт чиккән,
Хәзер безнең шобага.

Совет үзебезнеке,
Ил үзе дә безнеке.
Безне һичкем җиңә алмас,
Бөтен дөнья безнеке.

Бөтен җир-сулар безнеке,
Ис китми вак-төяккә;
Дөньяда тормыш калмасын
Буржуйга, аксөяккә.

Олы-кече, бергәләшеп,
Илгә хезмәт итәрбез;
Бергәләшеп хезмәт итсәк,
Рәхәт гомер итәрбез.

Вахит белән Хөбби кереп артта карап торалар.

Без үстердек буйларны,
Ашлык, сарык, куйларны;
Җиң сызганып, уйнап-көлеп,
Без итәбез туйларны.

Без килмәдек китәргә,
Килдек туйлар итәргә;
Насыйп булсын ике яшькә
Рәхәт гомер итәргә.

Карт *(Вахит белән Хөббине күреп)*. Яшьләр, балалар, юл бирегез, карт белән карчык килә. Хафиз, атаң белән анаңны каршы ал. Кайда син, Нигъмәт, китер үзләренә бал!

Хөбби. Ярабби Ходаем, картайган көнемдә бар икән күрәселәрем! Аһ-һа-һай! *(Кычкырып елый башлый.)*

Карт. Тукта әле, Хөбби! Нәрсә булды тагын сиңа? Кеше шатланып туй иткәндә, син авыз күтәреп елап торасың. Әйдәгез менә монда, кода-кодагый булып түрдән утырыгыз.

Икесенә дә урын бирәләр, Вахит белән Хөбби утыралар.

Карт. Менә шулай, менә шулай. Кеше шатланып туй иткәндә, син тагы авыз күтәреп елап торасың.

Вахит. Анысына синең исең китмәсен. Хатыннарның, карчыкларның аларның шулай булыр инде. Алар шатлансалар да, кайгырсалар да шулай авыз күтәреп елаудан башканы белмиләр.

Хөбби. Ник, менә тагы, шулай шул, дөрес түгелмени? Шулай шул, безнең кайгыбыз да, хәсрәтебез дә шул инде. Бала... бит... ул... Аһа-һа-һа...

Карт. Кайда, Нигъмәт, тизрәк китер балыңны, йөрәге басылсын.

Нигъмәт бал китерә. Карт, алып, Вахит белән Хөббигә бирә.

Хөбби.
Вахит. } *(балны алып)*. Рәхмәт. Ярый, исән булыгыз.

Эчәләр.

Карт *(Хөбби эчкәндә)*. Хөппи, Хөппи, Хөппи, хуп! Менә шулай, менә шулай! *(Пауза.)* Йә инде, кызлар, егетләр, туйның җитешмәгән җире калмасын, бер җырлап та бирегез.

Егетләр. Әйдәгез, әйдә, җырлыйбыз.

Давыт *(тәрәзәне ачып)*. Хафизә апа! Хафиз абый! Мин дә керим инде! Мин бит сезне бик яратам.

Хафиз һәм егетләр. Әйдә, кер, кер!

Давыт *(атылып кереп)*. Менә рәхмәт, Хафизә апа! Хафиз абый! Валлаһи менә, мин сезнең икегезне дә бик яратам. *(Бер җиргә чүгәли.)*

Гармунчы уйный башлый, кызлар белән егетләр күмәк җыр белән «Хафизәләм» көенә җырлыйлар.

